ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**И.И. Сабитова**

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЬЯСАЛЫШ СҮЗЛЕГЕ
## «КЕШЕ» ТЕМАТИК ТӨРКЕМЕНӘ КАРАГАН ЛЕКСИКА

КАЗАН • 2015

**УДК 811.512.145'374**
**ББК 81.2Тат-4**
**С 12**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

«2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре
һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау,
өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында
нәшер ителә

**Җаваплы редакторлар:**
филология фәннәре докторы, профессор **Ф.Ә. Ганиев,**
филология фәннәре докторы, профессор **К.Р. Галиуллин**

**Бәяләүчеләр:**
филология фәннәре кандидаты **Ф.Ф. Гаффарова,**
филология фәннәре кандидаты **О.Н. Галимова**

**Сабитова И.И.**
**С 12** **Татар теленең сүзьясалыш сүзлеге: «кеше» тематик төркеменә караган лексика** / И.И. Сабитова. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 160 б.
ISBN 978-5-93091-172-5

Бу сүзлектә татар телендәге «кеше» сүзенә караган лексик берәмлекләр сүзьясалыш ояларына туплап бирелде. Ояларда урнашкан ясалма сүзләрнең алфавит тәртибендә аерым исемлеге дә тәкъдим ителде. Һәрбер ясалма сүз үзе урнашкан ояның нумерациясенә туры килгән индекс белән урнаштырылды. Хезмәт татар филологиясе галимнәренә, укытучыларга, студентларга, мәктәп укучыларына тәкъдим ителә һәм татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен дә уңайлы кулланма була ала.

**УДК 811.512.145'374**
**ББК 81.2Тат-4**

**ISBN 978-5-93091-172-5**

© Сабитова И.И., 2015
© ТӘһСИ, 2015

# КЕРЕШ СҮЗ

Сүзьясалышы оясының продуктивлыгы грамматик, лексик һәм стилистик факторларга бәйле. Татар телендә «кеше» тематик төркеменә караган лексика зур сүзьясалыш потенциалына ия, чөнки бу төркемнең күпчелек сүзләре татар теленең төп лексик фондына керә, аралашуда еш кулланылалар һәм тотрыклы сүзләр булып саналалар. Сүз төркеме ягыннан алар исемгә карыйлар һәм стиль ягыннан нейтраль булулары белән характерланалар.

Бу сүзлектә «кеше» темасына караган лексик берәмлекләр сүзьясалыш ояларына туплап бирелде һәм, шулай итеп бу тематик төркемгә кергән ясалма сүзләрнең сүзьясалыш структурасы күрсәтелде, аларның сүзьясалыш потенциалының бөтен мөмкинлекләрен билгеләргә һәм ачыграк, тулырак итеп күрсәтергә тырышылды. Сүзлекне төзүдә төп принцип сыйфатында тамыр сүз һәм аның нигезендә барлыкка килгән тамырдаш сүзләрне оялап бирү принцибы алынды. Күренекле телче А.Н. Тихонов тарафыннан сүзьясалышы оялары принциплары буенча төзелгән һәм лексикография өлкәсендә югары бәя алган рус теленең ике томлы сүзьясалыш сүзлеге, К.Г. Ишбаев һәм З.К. Ишкилдина төзегән башкорт теленең сүзьясалыш сүзлеге үрнәк булды. Татар тел белемендә сүзьясалыш сүзлекләренә караган ике сүзлек билгеле. Беренчесе – А.М. Ямалетдинова һәм И.А. Латыйпова тарафыннан «Кеше. Кеше тәне (организмы) өлешләре» дигән тематик төркем материаллары буенча төзелгән «Русча-татарча тематик сүзьясалышы сүзлеге» Башкортостанның Туймазы шәһәрендә 2007 елда дөнья күрде. Шул ук елда Ф.С. Сафиуллина, З.Н. Кириллова, Ә.Ш. Юсупова һәм И.Г. Мифтахова

тарафыннан төзелгән «Татарча-русча тамырдаш сүзләр сүзлеге» Казан федераль университеты нәшриятендә басылып чыкты. Бу сүзлекләрнең дә уңай яклары әлеге хезмәттә чагылыш тапты.

Татар телендә сүзьясагыч кушымчалар, гадәттә, нигез сүзне үзгәртмичә, аңа турыдан-туры ялганып, яңа сүзләр ясыйлар. Сүзлектә кайсы сүзьясалыш нигезенә нинди сүзьясагыч чаралар кулланып, нинди яңа сүзләр ясалганы ачып бирелде. Нигез сүзләрнең сүзьясалыш оялары эчендә деривацион таралышы һәм мөмкинлекләре ачыкланды.

Ояга кергән ясалма сүзләрнең күпчелек өлешен кушымчалау ысулы белән ясалган синтетик сүзләр тәшкил итә. Бу юл белән күбрәк исемнәр, аннан сыйфатлар, фигыль һәм рәвешләр дә ясала. Кушымчалаудан тыш, бу төркем кысаларында күпсанлы кушма сүзләр, шул исәптән парлы сүзләр дә ясала. Парлы сүзләргә мисал итеп *эч-бавыр, эч-баш, эч-карын, эчәк-бавыр, йөз-кыяфәт* һ.б. китерергә мөмкин. Бу ояларда компонентлары кушылып язылган кушма сүзләр дә күп: *икейөзле, керфеккорсаклылар, йөззурлык, үрдәкборын, озынборын, каратүш, тәнкисәр* һ.б.

Татар телдә сүзьясалыш системасының тагын бер үзенчәлеге – аналитик конструкцияләрнең күп булуы. Бу үзенчәлек «кеше» дигән тематик төркемгә караган сүзләрдән ясалган ояларда да чагыла: *бит алмасы, борын канаты, борын яфрагы* һ.б. Шул ук вакытта бу төркем кысаларында биология, медицина өлкәләренә караган күпсанлы терминнар да ясала: *дагаборынлылар, үрдәкборын, йомшактәнлеләр, карга борыны, тәнкисәр, кызылтүш, күкрәк куышлыгы* һ.б.

Тәкъдим ителә торган әлеге сүзлек ике бүлектән тора. Сүзьясагыч ояларны тәшкил иткән төп бүлектән соң, ояларга урнаштырылган ясалма сүзләрнең алфавит тәртибендәге исемлеге дә тәкъдим ителә. Һәрбер ясалма сүз янында ул урнашкан ояның нумерациясенә туры килгән индекс бирелә.

Сүзлектә барлыгы 3325 сүз туплап бирелде. Шуларның 3147се ясалма сүз һәм алар 178 ояга урнаштырылды.

Әлеге сүзлек татар теленең сүзьясалышын өйрәнүчеләр өчен файдалы кулланма булачак.

## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

Сүзлеккә «кеше» лексик-тематик төркеменә караган нигез сүзләр сүзьясалыш оялары белән алфавит тәртибендә туплап бирелде:

**АВЫЗ** *и. анат.*
авыз-**ландыр**(*у*) *ф.*
...

**АҢКАУ I** *и. анат.*
аңкау-**лы** *с.*
...

**АРКА** *и. анат.*
арка-**даш** *и.*
...

Деривацион оялар үзләренең сүзьясалыш бәйләнешләрен саклаган тамырдаш сүзләрне эченә алды.

Кайбер очракларда (мәсәлән, *кимерчәк, йоткылык, имчәк, калак сөяге, калкансыман биз* һ.б.) ясалма сүзләрне дә сүзлеккә кертү өчен, бу сүзләрне ясый торган лексемалар ояның нигез сүзе итеп алынды:

**ЙОТ(У)** *ф.*
йот-**кылык** *и. анат.*
йот-**кыч** *и. махс.*
йот-**ма** *и. гади с.*
йот-**ым** *и.*
йотым-**ла**(*у*) *ф.*
йот-**кылык** биз-*е и. анат.*
йот-**кылык** гөмбә-**з**-*е и. анат.*
...

Бу нигез сүзләр үзләренең сүзьясалыш оялары белән сүзлек мәкаләсен тәшкил итә.

Ояның баш сүзе туры кара баш хәрефләр белән бирелде, сүзьясагыч кушымчалар кара юл хәрефләре, формаясагыч кушымчалар якты курсив белән аерылдылар:

**МАҢГАЙ** *и. анат.*

маңгай-**лы** *с.*

маңгай-**сыз** *с.*

маңгай-**ча** *и.*

маңгайча-**лы** *с.*

маңгайча-**сыз** *с.*

маңгай-*га*-маңгай *рәв.*

...

Ояда кушма сүзләр кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләрдән соң бирелде. Аларның өч төре дә (саф кушма, парлы һәм тезмә сүзләр) компонентлары саны буенча берничә ояга кертелде:

**КУЛ I** *и. анат.*

...

кул/баш *и. к.* **баш**

кул/баш сөя*г-е* *и. анат. к.* **баш, сөяк** [к//г]

...

**БАШ** *и. анат.*

...

кул/баш *и. к.* **кул**

кул/баш сөя*г-е* *и. анат. к.* **кул, сөяк** [к//г]

...

**СӨЯК** *и. анат.*

...

кул/баш сөя*г-е* *и. анат. к.* **баш, кул** [к//г]

...

Бу бары тик сүзлеккә кертелгән оялар эчендә генә эшләнде. Сүзьясалыш оясы эчендә кушма сүзләрнең урнашу тәртибе түбәндәгечә: башта ясаучы нигез (баш сүз) белән барлыкка килгән сүзләр икенче компонентларның алфавит тәртибендә бирелеше белән урнаштырыла, алардан соң килгән сүзләр ясаучы нигез (баш сүз) икенче урында булып, беренче компонентлар алфавит тәртибендә бирелде. Шушы тәртиптә элек компонетлары парлы, аннары кушылып, соңыннан аерым язылган сүзләр бирелде:

**АЯК I** *и. анат.* Әгъза

…

аяк-кул *җый. и. к.* **кул**

…

аяг/үрә рәв. [к//г]
аяк/чу җый. *и.*
аяк бит-е *и. к.* **бит**

…

баш-аяк *җый. и. к.* **баш**
алтын/сыман каз/аяк *и. бот.*
баш/аяк *рәв. гади с. к.* **баш**

…

агу-лы каз/аяк *и. бот.*

…

Алынма сүзләр, татар теленең үз сүзьясагыч кушымчалары кушылып, яңа лексик берәмлекләр ясаган очракта гына баш сүз итеп китерелде һәм аларның кайсы телдән алынганлыклары тиешле шартлы билгеләр белән күрсәтелде.

**БРОНХ** *и. гр. анат.*
бронх-**лы** *с.*
бронх-**сыз** *с.*

…

Әгәр дә баш сүз татар телендә аерым кулланылмаса, ул сүз ояның баш сүзе ролендә килеп, аңардан соң ике нокта куелды, аннан шул сүз кергән тезмә, ясалма сүз булып, аерым бер ояга кертелде:

**ЧӘКӘЛ:**
чәкәл буын-*ы* *и. анат. к.* **буын**
чәкәл сөяг-*е* *и. анат. к.* **сөяк** [к//г]

…

Сүзләрнең кайсы сүз төркеменә каравы грамматик тамгалар белән күрсәтелде: *и.* (исем), *ф.* (фигыль), *с.* (сыйфат), *рәв.* (рәвеш), *сан* (сан), *бәйл.* (бәйлек), *кис.* (кисәкчә):

**МУЕН** *и. анат.*
муен-**лы** *с.*
муен-**нан** *рәв.*
муен-**са** *и.*

муенса-**лы** *с.*

...

Стилистик яктан нейтраль булмаган сүзләрнең аерым билгеләр белән кайсы стильгә каравы күрсәтелде:

**МИ I** *и. анат.*

ми-**ле** *с.*

ми-**сез** *с. сөйл.*

...

Терминнар тармак билгеләре белән тамгаландылар:

**БОРЫН I** *и. анат.*

борын-**ла**(*у*) *ф.*

борын-**лач** *и. зоол.*

борын-**лаш**(*у*) *ф. лингв.*

...

Ояның баш сүзе бу тематик төркемгә карамаган икенче бер сүз белән омонимлашкан очракта, алар бер-берсеннән рим цифрлары белән аерылып, мөстәкыйль оялар рәвешендә бирелде:

**БИТ I** *и. анат.* Йөз

бит-**ләү** *и.*

...

**БИТ II** *и.* Китап һ.б. бите

бит-**ләп** *рәв.*

...

**БИТ III** *кис.*

Сүзъясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган сүзләр нигез сүздән аста, баскычлап артка таба чигерә барып урнаштырылды:

**МЫЕК** *и. анат.*

мыек-**лач** *и. зоол.*

мыек-**лы** *с.*

мыек-**сыз** *с.*

мыек-**ча** *и.*

мыекча-**лы** *с.*

мыекча-**сыз** *с.*

мыекчасыз-**лар** *и. күпл. зоол.*

мыек-**чан** *с.*

...

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН СҮЗЛЕКЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


## Аңлатмалы сүзлекләр

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда / редкол.: Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров, Ш.С. Ханбикова; СССР ФА КФ Г. Ибраһимов ис. ТӘТИ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977 – 1981.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / баш ред. проф. Ф.Ә. Ганиев. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 832 б.

Тимергалин А. Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек / А. Тимергалин. – Казан: Мәгариф, 2007. – 575 б.

## Татарча-русча сүзлекләр

Татарско-русский словарь. Ок. 38 000 слов. – М.: Сов. Энциклопедия, 1966. – 863 с.

Татарско-русский словарь: в 2-х т. – Казань: Магариф, 2007.

Татарча-русча тамырдаш сүзләр сүзлеге / төз.: Ф.С. Сафиуллина, З.Н. Кириллова, Ә.Ш. Юсупова, И.Г. Мифтахова. – Казан: Каз. дәүләт ун-ты, 2007. – 468 б.

## Диалектологик сүзлекләр

Татар теленең диалектологик сүзлеге / төз.: Н. Борһанова, Л. Мәхмүтова, З. Садыйкова, Г. Якупова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – 643 б.

Татар теленең диалектологик сүзлеге / редкол.: М.З. Зәкиев, Д.Б. Раманова (җав. ред.). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 459 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

## Этимологик сүзлекләр

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г. Әхмәтьянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: 4 томда / Р.Г. Әхмәтьянов. – Бирск: Бирск. гос. пед. ин-т, 2005. – Т. 1: (А–Й). – 233 б.

## Терминология сүзлекләре

Азбука природы: русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов: в 6 кн. / сост. А.Б. Халидов, А.С. Казанцева. – Казань: Магариф, 1996. – Кн. 1: Растения, грибы. – 111 с.

Азбука природы: русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов: в 6-кн. / сост. А.Б. Халидов. – Казань: Магариф, 1997. – Кн. 2: Насекомые. – 95 с.

Азбука природы: русско-татарский, татарско-русский словарь / сост. А.Б. Халидов, В.И. Гаранин. – Казань: Магариф, 2001. – Кн. 3: Птицы. – 95 с.

Азбука природы: русско-татарский, татарско-русский словарь / сост. А.Б. Халидов, В.И. Гаранин. – Казань: Магариф, 2001. – Кн. 4: Млекопитающие. – 119 с.

Азбука природы: русско-татарский, татарско-русский словарь / сост. Ф.Г. Ситдикова, А.А. Гайнуллин, Ф.Г. Иштирякова. – Казань: Магариф, 2001. – Кн. 5: Человек: анатомия, физиология, гигиена.

Биологический русско-татарский толковый словарь / под ред. Ф.Г. Ситдикова, Р.К. Закиева. – Казань: Магариф, 1998. – 664 с.

Закиров Ф.Д. Агулы үсемлекләр / Ф.Д. Закиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 536 б.

Краткий русско-латино-татарский словарь анатомическх терминов / сост.: Р.И. Ситдикова, Н.В. Михайлов, С.А. Сагеева и др. – Казань, 2002. – 52 с.

Медицинский русско-татарский толковый словарь / М.М. Гимадеев, Н.Х. Амиров, К.Ш. Зиятдинов; под общ. ред. М.М. Гимадеева. – Казань: Магариф, 2003. – 559 с.

Миннебаев М.М. Краткий русско-татарский словарь медицинских терминов / М.М. Миннебаев. – Казань: Медицина, 1994. – 260 с.

Руско-татарский словарь биологических терминов / сост.: Р.Г. Минибаев, И.Ш. Макалеев, А.Х.Гарифуллина и др. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1972. – 168 с.

Руско-татарский словарь биологических терминов / сост.: Ф.Ғ. Ситдиков, Н.А. Бакаева, А.Х. Ғарифуллина, И.Ш. Макалеев, Р.Х. Файзрахманова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – 198 с.

Русско-татарский словарь медицинских терминов / М.М. Гильманов, Н.Х. Амиров. – Казань: Магариф, 2000.

Русско-татарский словарь-минимум для работников здравоохранения / сост. Р.Р. Шамсутдинова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. – 76 с.

Русско-татарский толковый словарь медицинский терминов / сост. Р.Р. Шамсутдинова. – Казань: Магариф, 2004. – 351 с.

Русско-татарский толковый словарь терминов по ветеринарной медицине / сост. Ф.Г. Набиев, Р.Г. Госманов, Р.И. Ситдиков и др. – Казань: Магариф, 2004. – 364 с.

Саберова Г.Г. Татарча-русча-латинча үсемлек атамалары сүзлеге / Г.Г. Саберова. – Казан: Фикер, 2002. – 95 б.

Ямалетдинова А.М. Тематический русско-татарский словообразовательный словарь (на материале тематической группы «Человек. Части человечского тела (организма)») / А.М. Ямалетдинова, И.А. Латыпова. – Туймазы, 2007. – 119 с.

### Башка телләрнең сүзлекләре

Ишбаев К.Ғ., Ишкилдина З.К. Башҡорт теленең һүҙьяһалыш һүҙлеге / К.Ғ. Ишбаев, З.К. Ишкильдина. – Өфө: Ғилем, 2005. – 552 б.

Ишбаев К.Ғ., Ишкилдина З.К. Башҡорт теленең ҡыҫҡаса һүҙьяһалыш һүҙлеге / К.Ғ. Ишбаев, З.К. Ишкильдина. – Өфө: Ғилем, 2014. – 552 б.

Словарь физиологических терминов / отв. ред. О.Г. Газенко. – М.: Наука, 1987. – 446 с.

Тихонов А.Н. Словообразовательный словарь русского языка: в 2-х т. / А.Н. Тихонов. – М.: Рус. яз. – Т. 1. – 1990. – 856 с.; Т. 2. – 1990. – 886 с.

### Энциклопедик сүзлекләр

Энциклопедический словарь медицинских терминов: в 3-х т. / гл. ред. Б.В. Петровский. – М.: Сов. энцикл., 1982–1984. – Т. 1. – 1982. – 404 с.; Т. 2. – 1983. – 448 с.; Т. 3. – 1984. – 512 с.

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*анат.* – анатомия
*астр.* – астрономия
*әд.* – әдәбият
*бәйл.* – бәйлек
*биол.* – биология
*бор.* – борынгы (сүз)
*бот.* – ботаника
*бүл.* – бүлем (саны)
*гади с.* – гади сөйләм
*геогр.* – география
*гар.* – гарәп
*гр.* – грек
*диал.* – диалекталь сүз
*җый. и.* – җыйма исем
*зоол.* – зоология
*и.* – исем
*иск.* – искергән сүз
*к.* – кара
*кимс.* – кимсетеп әйтү
*кис.* – кисәкчә
*кит.* – китап теле
*кулин.* – кулинария
*күпл.* – күплек (сан)
*күч.* – күчмә мәгънәдә
*лат.* – латин
*лингв.* – лингвистика
*мат.* – математика
*махс.* – махсус
*мед.* – медицина
*неол.* – неологизм
*орф.* – орфография
*рәв.* – рәвеш
*с.* – сыйфат
*сан* – сан
*сир.* – сирәк кулланышта
*сөйл.* – сөйләү телендә
*тар.* – тарихи
*тәрт.* – тәртип (саны)
*тех.* – техника термины
*туп.* – тупас сүз
*ф.* – фигыль
*физ.* – физика
*физиол.* – физиология
*фр.* – француз
*эвф.* – эвфемизм
*этногр.* – этнография

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Аа | Дд | Зз | Мм | Пп | Үү | Чч | ь |
| Әә | Ее | Ии | Нн | Рр | Фф | Шш | Ээ |
| Бб | Ёё | Йй | ң | Сс | Хх | Щщ | Юю |
| Вв | Жж | Кк | Оо | Тт | Һһ | ъ | Яя |
| Гг | Җҗ | Лл | Өө | Уу | Цц | Ыы | |

ЭЧТӘЛЕК

Кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Сүзлекнең төзелеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Файдаланылган сүзлекләр исемлеге . . . . . . . . . . . . . . . 9
Шартлы кыскартылмалалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Татар алфавиты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Кеше» сүзенә караган лексик-тематик төркемнең сүзьясалыш оялары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Ояларда урнашкан ясалма сүзләр . . . . . . . . . . . . . . . . 117

Справочное издание

***Сабитова Ильгамия Исламутдиновна***

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА:**
**ЛЕКСИКА ТЕМАТИЧЕСКОЙ ГРУППЫ «ЧЕЛОВЕК»**
(на татарском языке)

Редактор *Я.М. Абдулкадырова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать 28.10.2015.
Формат 60×84$^1/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman
Печать офсетная. Усл. печ. л. 9,3. Уч.-изд.л. 3,3. Тираж 600. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. Лобачевского, 2/31

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20